КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1505

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2013 ел, 10 июнь, 394 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2013 ел, 10 июнь, 394 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 гыйнвар, 27 нче; 2022 ел, 19 апрель, 366 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Фонд тарафыннан алынган һәм капиталь ремонт фондын барлыкка китерә торган акча Фондның капиталь ремонт фондлары акчасын урнаштыру өчен ачылган счетында (счетларында) исәпкә алына һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 174 статьясында күрсәтелгән максатларда гына файдаланыла ала. Әлеге акчаны башка максатлар өчен, шул исәптән Фондның административ-хуҗалык чыгымнарына түләү өчен кулланырга рөхсәт ителми.»;

3.6 пунктта «шулай ук» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Торак кодексының 167 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракта күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җиһазлар, шул исәптән югары технологияле җиһазлар) белән тәэмин итү шартнамәләреннән һәм» сүзләрен өстәргә;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Фонд бөлгенлек (банкрот) дип танылa алмый.»;

4.1 пунктның алтынчы һәм җиденче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;

6.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Фондны гамәлгә куючы аны бетерү турында карар кабул итәргә хокуксыз.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин